# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Кыр Шонталысы авыл җирлеге составына керүче Кыр Шонталысы авылы

14 ноябрь 2019 ел. № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Кыр Шонталысы авыл җирлеге составына керүче Кыр Шонталысы торак пунктында гражданнар җыены

**Карар итте**:

1. 2020 елда Кыр Шонталы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге чараларга юнәлдерергә:
   - җирлек эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау;;
   - техниканы карап тоту (трактор, янгын сүндерү машинасы, килешү буенча хезмәт хакы);
   - торак пунктта урамнарны яктыртуны карап тоту;

3. Әлеге карарны Кыр Шонталысы авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Кыр Шонталысы авыл җирлеге мәгълүмат стендында урнаштырырга, адресы: Татарстан Республикасы Алексеевск районы, Кыр Шонталы авылы, Вахитов урамы, 34 нче йорт.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кыр Шонталысы авыл җирлеге башлыгы Ф.Я.Хамадеев